**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ПР-236 от 30.10.2024 № _____

«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген хосусый милектәге җир кишәрлегенә алмаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 мартындагы ПР-43 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы, һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 04 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген хосусый милектәге җир кишәрлегенә алмаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 5 пунктчасында «күрсәтелгән чорда» сүзләреннән соң «аның максатчан билгеләнеше һәм» сүзләрен өстәргә, «муниципаль берәмлеккә һәм белгечлеге буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән муниципаль берәмлек, һәм һөнәре, белгечлеге буенча» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов